ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ДИМТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

№ 7 Димтамак авылы 17 июнь 2020 ел

**IV чакырылыш Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге советына депутатлар сайлауларын билгеләү турында**

2002 елның 12 июнендәге «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында»гы 67-ФЗ санлы Федераль законның 10 маддәсе, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 23 маддәсе, 2007 елның 7 маендагы 21-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы сайлау кодексының 105 маддәсендәге 1 өлеше, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Димтамак авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 12 маддәсе нигезендә, Димтамак авыл җирлеге советы к а р а р и т т е:

1. IV чакырылыш Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге советының депутатлар сайлауларын 2020 елның 13 сентябренә билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Ютазы таңы» («Ютазинская новь») газетасында бастырырга һәм кабул ителгән көннән биш көннән дә соңга калмыйча http://jutaza.tatarstan.ru электрон адресы буенча ТР Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, ТР муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырырга кирәк.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Димтамак авыл җирлеге башлыгы И.Ә.Сәләмов